Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге Советының унтугызынчы утырышы

Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

10 октябрь, 2022 ел № 50

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы, Татар Тау Иле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында» 2021 елның 9 апрелендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә 2022 елның 1 октябреннән арттырырга. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкыр индексләштырырга һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татар Тау Иле авыл җирлеге
башлыгы урынбасары Э.Ф. Әхмәтова